Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 2-31 номерлы карары

**2024 елда «Казанның Мактаулы гражданины» исемен бирү турында**

«Казанның Мактаулы гражданины» исеме турында нигезләмәгә таянып, Казан шәһәре Мэры И.Р.Метшин тәкъдимен карап тикшергәннән соң, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. «Казанның Мактаулы гражданины» исемен бирергә:

**Хөснуллин Марат Шакирҗан улына** – Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасарына, – Казан шәһәренең социаль-икътисади үсешенә һәм аның уңышларга ирешүенә гаять зур шәхси өлеш керткәне өчен;

**Җәббарова Роза Шәрифулла кызына** – «Горводзеленхоз» шәһәр су һәм яшелләндерү хуҗалыгы җитештерү тресты» муниципаль унитар предприятиесе идарәчесенә, – күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Казан шәһәренең тышкы төзекләндерү тармагын үстерүгә саллы өлеш керткәне, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен.

2. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына Казанның Мактаулы гражданнары исемнәрен «Казанның Мактаулы гражданнары» китабына кертергә, Казанның Мактаулы гражданины грамотасын, таныклыгын, лентада «Казанның Мактаулы гражданины» билгесен, билгенең кечерәйтелгән күчермәсен тантаналы рәвештә тапшыруны оештырырга һәм, Казан шәһәренең муниципаль бүләкләре турында нигезләмәгә таянып, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм аны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**